Татарстан Республикасы

Чирмешән муниципаль районы

Иске Котыш авыл җирлеге

гражданнары җыены карары

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлеге составына керүче Кызыл Яр авылы торак пунктында

8 ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Котыш авыл җирлегенең Кызыл Яр авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2020 елда Иске Котыш авыл җирлегенең Кызыл Яр авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш.

2. Алынган чараларны җибәрергә:

- җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, тракторчыга хезмәте өчен түләү, запас частьләр сатып алу), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Кызыл Яр, Яңа Котыш, Иске Котыш торак пунктларында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- җәмәгать киңлекләрен (халык күпләп ял итә торган урыннарны) төзекләндерү;

- Иске Котыш торак пунктында сууткәргечнең проект-смета документларына экспертиза ясау өчен.

Халык җыенында рәислек итүче
Иске Котыш авыл җирлеге башлыгы А.К.Митякин